**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

02 ноябрь 2021 ел — Боерган авылы — № 13

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 8 февраленнән 3 нчы санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру «Федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында "гы карарны тормышка ашыру максатларында

**КАРАР БИРӘ:**

1.Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 8 февраленнән 3 нче санлы карары белән расланган «2021—2023 нче елларга Боерган авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына 2021 нчы ел өчен финанслау күләменең 70 мең сумга, 2022 нче ел өчен 165 мең сумга артуы сәбәпле түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1.1. «2021—2023 нче елларга Боерган авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының “Күләм һәм финанслау чыганаклары” бүлемтәсен яңа редакциядә бәян итәргә:

1,2. «2021—2023 нче елларга Боерган авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының 3,4,6 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

3.Программаны Финанслау.

Программаның гомуми финанслау күләме 565 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финанс белән тәэмин итүче-авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район башкарма комитеты җитәкчесе.

Тиешле финанс елына бюджетны формалаштырганда финанслауның күрсәтелгән күләмнәре төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкинлек булганда район бюджеты акчасы, максатчан һәм ирекле иганәләр дә җәлеп ителәчәк.

1.3 «2021—2023 нче елларга Боерган авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасын яңа редакциядә бәян итәргә:

2021—2023 нче елларга Боерган авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасы

| № | Объектның исеме | куәте | финанслау чыганаклары | | | искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Җирле бюджет, | | | |
| | | | 2018 | 2019 | 2020 | |
| 1 | Авыл эче юлларын төзү, төзәтү, реконструкцияләү | 150м | | 85,0 | 85,0 | |
| 1.1 | Туера авылы Красноармейская урамы | | | | | |
| 1.2 | Колыш авылы Тельман урамы | | | | | |
| 1.3 | Боерган авылы Новая урамы | 150м | | 85,0 | 85,0 | |
| 2 | Торак пунктларда тукталыш павильоннары урнаштыру | - | 30,0 | | | |
| 3 | Балалар өчен автомобиль мәйданчыклары урнаштыру | - | 100,0 | - | - | |
| 3.1 | Туера авылында автобус борылу мәйданчыгы | | 100,0 | | | |
| 4 | "Ясалма тигезсезлек" кую | - | - | 110,0 | - | |
| 5 | Юлларны тамагалау | - | 15,0 | 15,0 | 15,0 | |
| 6 | Юл йөрү билгеләре урнаштыру | - | 55,0 | 55,0 | - | |
| 7 | Юл кыры сервислары урнашкан урыннарда яктырткычлар кую | - | - | | - | |
| 8 | Металл барьер коймасы урнаштыру | - | - | - | - | |
| 9 | Торак пунктларда юл йөрүне оештыруны проектлау | - | | - | - | |
| | Барысы | - | 200,0 | 265,0 | 100,0 | |

Программаның гомуми финанслау күләме 565 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финанс белән тәэмин итүче-авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район башкарма комитеты җитәкчесе.

Тиешле финанс елына бюджетны формалаштырганда финанслауның күрсәтелгән күләмнәре төгәлләштерелергә тиеш.

2.Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Боерган авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Г.Г.Минакова